ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 октябрь 2020ел № 5388

Законсыз саклланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш припасларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаучан матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 номерлы статьясы, Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлегенең 87 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Законсыз саклланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 19 октябрендәге
5388 номерлы карарына
кушымта

Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – регламент) законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

Әлеге регламентның йогынтысы түбәндәгеләргә кагылмый:

- сигнал, старт, төзелеш-монтаж пистолетлары һәм револьверлары, электрошок җайланмалары, хуҗалык-көнкүреш һәм җитештерү билгеләнешендәге эшләнмәләр сыйфатында сертификацияләнгән предметлар, корал белән конструктив охшаш, корал дип саналмый торган спорт снарядлары;

- зарарлаучы элементлар (снаряд, пуля, ядрә, картечь һ.б.) булмаган һәм төзәгән урынга тидерү өчен билгеләнмәгән, сугыш припаслары, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаучан матдәләр дип саналмый торган сигнал, яктырту, буш, төзелеш, газ, уку һәм башка патроннар;

- шартлаучан матдәләр һәм шартлаткыч җайланмалар дип саналмаган имитация-пиротехник һәм яктырту чаралары.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет)

Муниципаль хезмәт күрсәтүне башкаручы: Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 427 кабинет.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр,

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә телефоны: (8552) 30-56-77.

Керү шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: (http://nabchelny.ru/company/2).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында, шулай ук Башкарма комитетның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://nabchelny.ru/company/37) аша;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru);

5) Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта аша электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Башкарма комитет белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм КФҮ бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Корал турында» 1996 елның 13 декабрендәге 150-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 150-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 16.12.1996, № 51, ст. 5681);

2) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

3) Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.05.2006, № 19, ст. 2060);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

5) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР законы) (Татарстан Республикасы, № 155-156, 03.08.2004);

6) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, сугыш припасларының, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаучан матдәләрнең законсыз әйләнештә йөрүен кисәтү чаралары турында» 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы карары (алга таба – нигезләмә);

7) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

8) Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге (алга таба – муниципаль хезмәтләр исемлеге);

9) Башкарма комитетның 2019 елның 8 маендагы 291-р боерыгы белән расланган Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмә (алга таба – халык иминлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмә;

10) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 25 февралендәге 101-р боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

- корал – тере булган яки башка нәрсәгә төзәп атуга, сигнал бирүгә конструктив билгеләнгән җайланмалар һәм предметлар;

- утлы корал – төзәгән снаряд ераклыгында механик төзәгән урынга тидерү өчен билгеләнгән, дары яисә башка заряд энергиясе исәбенә юнәлдерелгән хәрәкәтне алучы корал,

- шартлаткыч җайланмалар – шартлаучан матдәне функциональ яктан берләштерүче сәнәгать яки кулдан ясалган эшләнмәләр һәм шартлауны башлап җибәрү өчен җайланма (запал, шартлаткыч, детонатор һ.б.);

- шартлаучан матдәләр – тышкы тәэсирнең билгеле бер төрләрендә, җылылык һәм газлар ясалу белән тиз тарала торган химик әверелешкә сәләтле матдәләр;

- кулдан ясалган ату коралы һәм аның төп өлешләре – шул исәптән башка предметларны (мәсәлән, ракетницалар, пневматик, старт һәм төзелеш-монтаж пистолетлары, көнкүреш билгеләнешендәге предметлар яки спорт инвентарьлары) үзгәртү юлы белән булдырылган корал, нәтиҗәдә алар утлы корал үзлекләрен алалар;

- үзгәртеп эшләнгән корал – аларның тактик-техник характеристикаларының һәм үзлекләренең билгеләнгән тәртибен бозуга үзгәреш, мондый үзгәрешләр нәтиҗәләренә бәйсез рәвештә, аларның зарарлы үзлекләре саклана (мәсәлән, башка предметларны имитацияләү өчен аларның формалары үзгәрү, утлы шома коралның көпшәсен кисеп ясалган корал белән кораллануга үзгәртү, утлы шома коралның көпшәсен кыскарту, нәтиҗәдә ул әйләнешкә тыелган була һ.б.);

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) ул – муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункт). Гариза әлеге регламентның 1 нче кушымтасында каралган форма буенча тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандарт таләбенең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырганга акчалата түләү турында карар кабул итү | нигезләмәнең 2 пункты |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган җирле үзидарәнең башкарма-боеру органының исеме | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | шәһәр Уставы, халык иминлеген тәэмин итү бүлеге турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясенең ирекле рәвештә корал тапшырган өчен акчалата түләү турында карары яисә акчалата түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазе һәм акчалата түләүнең күләмен билгеләү | нигезләмәнең 7 пункты |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы, әгәр туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса | Гариза кергән көннән башлап 25 календарь көннән артмаган вакытта | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, мөрәҗәгать | Гариза (регламентка 1 нче кушымтада каралганча)<br>Паспорт яки Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне раслаучы башка документ.<br>Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль органы яки Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының | нигезләмәнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибенең тулы исемлеге | территориаль органы тарафыннан бирелә торган корал, сугыш припаслары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаучан матдәләр кабул итү турында квитанция (мәҗбүри тәртиптә барлык юллары да тутырылган булырга тиеш).<br>Акча күчерү өчен акчалата түләү алучы зат өчен ачылган банк реквизитлары (субсидия һәм пенсия счетларыннан тыш) (банкның исемен, ИНН, КПП, БИК, корр/счет һәм гариза бирүченең исәп-хисап счетын күрсәтеп). Әгәр банк реквизитлары кулдан язылган булса, ул очракта гариза бирүченең имзасы һәм имза расшифровкасы куела.<br>Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетка яки КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә КФҮ аша, КФҮнең ерактагы эш урыны аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган, шулай ук гариза бирүче аларны бирергә хокуклы, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>Салым органында исәпкә кую турында таныклык | нигезләмәнең 6 пункты |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү | Килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен килештерү (муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп ителә торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) документларның тиешле зат тарафыннан тапшырылмавы;<br>2) тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатмый торган җитди кимчелекләр булу;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру | 59-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган яисә тәкъдим ителгән гаризада һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булу;<br>2) Әгәр тиешле документны гариза бирүче үз инициативасы белән бирмәгән булса, дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, яисә дәүләт хакимиятенең ведомство буйсынуындагы органы, яисә җирле үзидарә органының муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны дәлилләүче ведомствоара запроска җавабы керү | 59-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 9 пункт |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, андый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел;<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә<br>Ял (бәйрәм) көнне электрон рәвештә кергән запрос ялдан (бәйрәмнән) соңгы эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәттән файдалану урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм аларда хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора: | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итүләре саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникацон технологияләрне файдаланып | документлар кабул итү һәм бирү бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында (http://www.nabchelny.ru), Татарстан Республикасы Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru) муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган барьерларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлекнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга | |

| | | |
|---|---|---|
| | таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче шәһәр сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, КФҮдә ала ала | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон рәвештә бирү законда каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi. tatar.ru/) аша яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Башкарма комитетка шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм документларны әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Башкарма комитет эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм килештерелмәгән башка төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм махсус журналда терки;

гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне үтәүнең датасы һәм вакыты турында билге куеп, бирелгән документлар исемлегенең күчермәсен тапшыра;

гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризаларны кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрне аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гариза һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә, башкаручыны билгели һәм гаризаны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлегенә җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге белгече (алга таба – бүлек белгече) ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә салым органында исәпкә кую турында таныклык бирү хакында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон рәвештә җибәрелгән запрос.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә соралган документларны (мәгълүматны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрә (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе).

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар документ һәм мәгълүмат бирүче органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.4.3. Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килүен тикшерә;

хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссия утырышында карап тикшерү өчен документлар пакеты әзерли;

документлар пакетын комиссия карап тикшерүенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар запроска җавап кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссиягә җибәрелгән документлар пакеты.

3.4.4. Комиссия секретаре гамәлгә ашыра:

кергән документларны өйрәнә;

комиссия утырышының датасын билгели;

комиссия әгъзаларына гаризаны карап тикшерү датасы турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар документлар комиссиягә кергән вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына комиссия утырышының датасы турында хәбәр итү.

3.4.5. Билгеләнгән көнне комиссия әзерләнгән документлар пакетын карап тикшерә һәм акчалата түләү һәм коралны ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар комиссия утырышы көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: акчалата түләү һәм коралны ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү күләмен билгеләү турында комиссия карары.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Бүлек белгече:

комиссия уңай нәтиҗә кабул иткән очракта, гариза бирүченең мәгълүматларын (паспорт мәгълүматларын, салым түләүченең идентификацион номерын, банк реквизитларын, акчалата түләүнең күләмен) «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУга җибәрелә торган акчалата түләүләр реестрына кертә һәм реестрга кертү турында хат проекты әзерли;

комиссия тискәре нәтиҗә кабул иткәндә, түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазе әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар комиссия нәтиҗәсе килгән көннән башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә – комиссия рәисенә имзалау өчен җибәрелгән реестрга кертү турында хат яки баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5.2. Башкарма комитет Җитәкчесе – комиссия рәисе реестрга кертү турында хатны яки баш тарту турында белдерү кәгазен имзалый һәм бүлек белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек белгеченә теркәү өчен җибәрелгән имзаланган хат.

3.5.3 Бүлек белгече акчалата түләү турындагы хатны яисә акчалата түләүдән баш тарту хакындагы белдерү кәгазен терки һәм гариза бирүчегә тапшыра яки почта аша җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту очрагында, гариза бирүчегә түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазе әзерли һәм аны гариза бирүчегә җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү очрагында, реестрга кертү турында хат әзерли һәм аны гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге регламентның 3.5.2 - 3.5.3 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар 3.5.1 пунктчасында каралган процедуралар тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче шәхсән үзе килгән очракта – 15 минут эчендә;

белдерү кәгазен почта аша җибәрү очрагында, алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә акчалата түләү турында җибәрелгән хат яисә түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.6. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә, КФҮнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. КФҮдән муниципаль хезмәттән файдалануга документлар алынганда, процедуралар әлеге регламентның 3.3 - 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче бүлеккә тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

юридик көчкә ия булган, техник хатаның булуын дәлилләүче документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә җибәрелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документлар кабул итүгә җаваплы белгече техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән терки һәм аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.7.3. Халык иминлеген тәэмин итү бүлеге белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имза куйдырып тапшыра яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша), халык иминлеген тәэмин итү бүлегенә техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда, документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынган көннән башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары түбәндәгеләр:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр дә карала ала.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең үтәлешен контрольдә тоту максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында аңлатма язулары тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы Башкарма комитетның вазыйфаи затлары исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турында нигезләмә һәм вазыйфаи инструкцияләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшерү өчен җаваплы.

Халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җавап тота.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм эш итүләр (эш итмәүләр) өчен Башкарма комитетның вазыйфаи затлары һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җавап тоталар.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитеты эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) – Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләренең – КФҮгә яисә гавами-хокукый берәмлекнең КФҮне оештыручы тиешле дәүләт хакимияте органына судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә гамәлләрне тормышка ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарту яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр туктату нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), КФҮнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, КФҮнең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдергән очракта яисә мондый хаталарны төзәтүнең билгеләнгән срокларын бозуга шикаять биргән очракта – теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять белдерелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яки Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүче – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның вазыйфаи затының яисә Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүче алар нигезендә Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карары һәм эш итүе (эш итмәве) белән риза булмаган дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә аларны түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә аның шикаятен карап тикшерү нәтиҗәләре турында мотивацияләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында гамәлгә ашырыла торган эш итүләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәттән файдалану өчен алга таба эш итүләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)
Башкарма комитеты» МКУ

____________________________________
(Ф.И.А.и.)
____________________________________
(паспорт мәгълүматлары)
____________________________________
(яшәү урыны буенча теркәлү)
______________________(алга таба – гариза бирүче)
(телефон)

Акчалата түләү турында
**Г А Р И З А**

Сездән минем тарафтан тапшырылган ______________________________________________________________
(корал, аның өлешләре, сугышчан припаслар, коралга патроннар, шартлаучан матдәләр һәм шартлаткыч җайланмалар)
өчен акчалата түләвегезне сорыйм__________________________________________________________
________________________________________________________________________
______________________________________________

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) шәхесне аныклаучы документлар;

2) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

3) салым органында исәпкә кую турында таныклык;

4) корал, сугышчан припаслар, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаучан матдәләрне кабул итү турында квитанция;

5) акча күчерү өчен банк реквизитлары.

______________ ____________ _____________________________
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), блокировкалау,

персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала. Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | __________________ | ________________________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф. И. А.и.) |

Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе
________________________________
___________________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________________________________________

(хезмәтнең исеме)
Язылган:____________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ___________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне: ________________________________________________________________________________.


Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплауга, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), блокировкалау, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала. Миңа

күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_______________ _________________ _______________________________)
(дата) (имза) (Ф. И. А.и.)

Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта



ХИТИБ белгече Комиссия утырышында карау һәм алга таба акчалата түләү яисә акчалата түләүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен документлар пакетын әзерли

Ирекле рәвештә корал тапшырган өчен акчалата түләү яисә акчалата түләүдән баш тарту турында һәм акчалата түләү күләмен билгеләү хакында комиссия карары

ХИТИБ белгече реестрга кертү хакында хатлар проектын яки акчалата түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазе әзерли

Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән реестрга кертү хаты яки акчалата түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазе

Башкарма комитет Җитәкчесе реестрга кертү хатын яки акчалата түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазен имзалый

ХИТИБ белгеченә җибәрелгән имзаланган хат

ХИТИБ белгече түләү турында хатны яки түләүдән баш тарту турында белдерү кәгазен терки һәм гариза бирүчегә яки КФҮгә җибәрә

Гариза бирүчегә яки КФҮгә җибәрелгән хат

Законсыз сакланган яки табылган коралны, сугыш припасларын, коралга патроннарны, шартлаткыч җайланмаларны һәм шартлаучан матдәләрне ирекле рәвештә тапшырган өчен акчалата түләү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
4 нче кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы | 30-55-58 | oobn424@yandex.ru |
| Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге белгече | 30-56-77 | oobn424@yandex.ru |